МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.05.2024 Казан ш № 333

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 27 гыйнварындагы 52 номерлы боерыгы белән расланган Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 27.01.2022 №52 боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 29.08.2022 №808 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының 2024
елның « 02 » маендагы 333 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 52 номерлы боерыгы белән расланган Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Преамбуланы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләрен өстәргә;

2.6.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның формаларын раслау турында» 30.01.2024 №32н боерыгына (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 32н номерлы боерыгы) 3 нче кушымта нигезендә гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Россиядә эш» порталын кулланып, Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә электрон документ рәвешендә җибәрелә.»;

2.6.4 пунктның бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.8.3 һәм 2.8.4 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.7.4 пункт белән тулыландырырга:

«3.7.4. Әлеге Регламентның 2.8.5 пунктында каралган шартлар килеп чыкса, эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында карар кабул ителә.

Үтәү вакыты: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында карар кабул ителгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатуны «Россиядә эш» порталында теркәлү.»;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.